СОВЕТ БОЛЬШЕПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЗУР ПОЛЯНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **с. Большие Полянки** **КАРАР**

**23.06.2026** **№ 21**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге Советының 16.11.2018 ел, № 83 «Җир салымы турында» карарына үзгәреш кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 30.10.2014 ел, № 82-ЗРТ Татарстан Республикасы Законына туры китереп,

**Зур Полянка авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 16.11.2018 ел, № 83 карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент:

торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган, эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләре һәм җир кишәрлекләре, аларның һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган;

шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган, шулай ук «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы

Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләре, әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган;»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Зур Полянка авыл**
**җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **Р.Р. Гайнуллин**